**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреленнән — № 9-61

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниипаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 8 сентябрендәге 26-199 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниипаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 8 сентябрендәге 26-199 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 16 мартындагы 32-249 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 пунктында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гамави хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

а) аның үлеме очрагында;

б) үз вәкаләтләрен туктату турында язма гариза;

в) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә сәләте чикләнгән дип танылу;

г) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яки вафат булган дип игълан ителү;

д) аңа карата суд хөкеменең законлы көченә керүе;

б) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгу;

ж) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

з) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) йә яшәү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;

и) депутатка карата Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, ул сайлануга кандидат буларак теркәлгән чорда чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану фактларын билгеләү;

к) аның чит ил агенты статусын алуы;

л) алты ай дәвамында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының барлык утырышларында нигезле сәбәпләрсез депутатның булмавы;

м) муниципаль район составында авыл җирлеге башлыгы, җирлекнең вәкиллекле органы депутаты буларак аның вәкаләтләрен туктату;

н) 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законында күрсәтелгән башка очракларда.

1.1. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып, әлеге статьяның 1 пунктында каралган нигезләрдән тыш, коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны күп тапкырлар үтәмәү тора.

Депутат тарафыннан коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны вәкаләтләр чоры дәвамында кимендә ике тапкыр үтәмәү депутатның коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) бурычларны үтәмәве дип танылa.

Депутат вәкаләтләре вакытыннан алда тукталган очракта, вакант депутат мандатын тутыру Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының төп гарантияләрен билгеләүче Федераль закон һәм Татарстан Республикасының Сайлау кодексы белән билгеләнгән тәртип буенча башкарыла.»;

1.3. 17 статьяның 1 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) Депутат, Россия Федерациясенең 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законында күрсәтелгән керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Рәисенә, билгеләнгән срокларда һәм бу Федераль закон белән билгеләнгән очракларда тәкъдим итүгә тиеш. Депутат, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законында күрсәтелгән чыгымнары турында мәгълүматны, бу Федераль закон белән билгеләнгән очракларда тәкъдим итә. Депутат, 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектларында публик хакимлекне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 3-6 статьяларында, коррупциягә каршы тору максатындагы башка Федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса»;

1.4. Нигезләмәнең 17 статьясының 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11,12,13,14,15 нче пунктчалар белән тулыландырырга:

«11) Депутатның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагı йөкләмәләре турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты раслаган белешмә формасы буенча тапшырыла.

12) Бу статьяның 10 пунктында күрсәтелгән очракларда, депутат түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

а) 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон нигезендә чыгымнар (хисап чоры) турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының (хисап чоры) керемнәре турында, барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) белешмәләр, шулай ук аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына булган мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алуның һәр алыш-биреше буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында тапшыру елыннан алдагы календарь ел дәвамында (алга таба - хисап чоры)белешмәләр, әгәр мондый алыш - бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса, һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.»;

13) район Советы депутаты үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Рәисе исеменә мәгълүмат бирә.

14) әгәр депутат керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылыш тапмавын яисә тулысынча чагылыш тапмавын йә хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә тапшырырга хокуклы. Депутат әлеге статьяның 10 пункты нигезендә белешмәләр бирелгән көннән алып бер ай эчендә төгәллләштерелгән белешмәләрне тапшыра ала.

15) объектив сәбәпләр аркасында депутат тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагя йөкләмәләре турында мәгълүмат бирелмәгән очракта, әлеге факт Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан каралырга тиеш.»;

1.5. Нигезләмәнең 18 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 нче статья. Депутатлык эшчәнлеген алып бару белән бәйле чикләүләр, тыюлар һәм бурычлар.

1. Депутат үз статусыннан депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле булмаган эшчәнлек өчен файдаланырга хокуксыз.

2. Үз вәкаләтләре чоры дәвамында депутат, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясе сенаторы, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, судья була алмый, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының башка дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, шулай ук муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмый.н очракларны исәпкә алмыйча, биләя алмый.

3. Депутат, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган нигезләр һәм тәртип булганда, депутат вәкаләтләрен гамәлгә

ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

4. Депутат Татарстан Республикасы Рәисенә һәм прокуратура органнарына законда каралган тәртиптә аны коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында аңа мөрәҗәгать итүнең барлык очраклары турында тиешле мөрәҗәгать көненнән биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

5. Депутат Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яки күзәтчелек советлары, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәткә карамаган оешмаларның һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә хокуклы түгел.

6. Депутатка, аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счет (кертемнәр) ачу һәм аның счеты (кертемнәре) булу, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела. Шул ук вакытта «чит ил финанс инструментлары» төшенчәсе Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнарында билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

7. Депутат Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору законнары белән билгеләнгән чикләүләрне, тыелуларны сакларга һәм бурычларны үтәргә тиеш.

8. Әгәр депутат әлеге статьяның 1 һәм 3 нче пунктларында каралган чикләүләрне, тыелуларны бозса һәм бурычларны үтәмәсә, 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законы белән каралган үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәсә, һәм 2012 елның 3 декабреннән 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законы белән каралган чыгымнары турында мәгълүмат бирмәсә, яки тулы булмаган мәгълүмат бирелсә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан йә белә торып дөрес булмаган белешмәләрдән тыш, депутатка карата түбәндәге җаваплылык чараларының берсе кулланылырга мөмкин:

а) кисәтү;

б) муниципаль вазыйфаны биләүче затны тиешле җирле үзидарә органындагы вазыйфасыннан азат итү һәм аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы тиешле җирле үзидарә органында вазыйфаларны биләү хокукыннан мәхрүм итү;

в) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

г) аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы тиешле җирле үзидарә органында вазыйфаларны биләүне тыю;

д) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

9. Депутатка карата әлеге статьяның 8 нче пунктында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа

Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский